**Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 19 октябре** **№ 27**

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 31 октябренә 13 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Сәрдек авылы, Яңа ур., 2А адресы буенча мәдәният йортында үткәрергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Сәрдек авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“-Яңа Сәрдек авылында су башнясын ремонтлау, карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру , артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;”

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы: Нәбиев И.М.

ОГРН 1021607752858 ИНН 1623001854